| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ГЛАЗОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ГЛАЗОВО<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 12 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Глазово торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 21 ноябрендәге 909 номерлы карары (25.11.2024 №1049 редакциясендә)белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы белән, Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегә башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Глазово торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 30 ноябрендә 08 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Глазово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан тыш, 2026 елда 700 (Җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру

өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Глазово авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Глазово авылында Дала, Совет, Елга аръягы, Ленин, Подгорная урамнары буенча юлларны ремонтлау, кардан чистарту)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Үрнәк-Күмәк ав., Мәктәп ур., 3а й., Глазово ав., Заречная ур., 13 й., Петропавловка ав., Горький ур., 19а й., Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Глазово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.К.Карабаева